КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 ел, 22 апрель

г.Казань

№ 385

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2018 ел, 18 сентябрь, 789 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2018 ел, 18 сентябрь, 789 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 8 октябрь, 914 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2019 - 2023» саннарын «2019 - 2024» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2019 - 2023» саннарын «2019 - 2024» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында (алга таба - Программа):

исемендә «2019 - 2023» саннарын «2019 - 2024» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган |

| | |
|---|---|
| | компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба - Программа) |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;<br>«Татарстан Республикасының Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе;<br>Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (килешү буенча) |
| Программаның максаты | Республикада гамәлдә булган газ заправкалары инфраструктурасын киңәйтү юлы белән компри-мировкаланган табигый газда (алга таба - КТГ), сыекландырылган табигый газда (алга таба - СТГ) эшләүче транспорт чараларын күчерүне һәм сатып алуны стимуллаштыру, шул исәптән заправкаларда электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен зарядка колонкаларын (станцияләрен) булуны исәпкә алып. |
| Программаның бурычлары | Яңа автомобиль газ белән тәэмин итүче компрессор станцияләрен (алга таба - АГТКС), криоген автомобиль ягулык салу станцияләрен (алга таба - КриоАЗС) төзү һәм файдалануга кертү, КТГ һәм СТГ ягулык белән тәэмин итү блокларын урнаштырып, күп ягулык салу станцияләрен яисә автомобильне газ белән тәэмин итү станцияләрен (алга таба - АЗС) реконструкцияләү яисә модернизацияләү, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләр) булуын исәпкә алып |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2019 - 2024 еллар.<br>I этап – 2019 ел;<br>II этап – 2020 ел;<br>III этап - 2021 ел;<br>IV этап - 2022 ел;<br>V этап - 2023 - 2024 еллар |
| Еллар һәм чыга-наклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 4 800,0 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән федераль бюджет акчалары исәбеннән - 842,16 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджетыннан - 633,84 млн.сум, бюджеттан тыш |

<table>
<tr><td></td><td>чыганаклардан - 3 324,0 млн.сум.<br>(млн.сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барлыгы акча</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджет акчасы</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклардан акча</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>240,0</td><td>0</td><td>80,0</td><td>160,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>840,0</td><td>117,6</td><td>162,4</td><td>560,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 200,0</td><td>213,84</td><td>146,16</td><td>840,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>840,0</td><td>100,8</td><td>151,2</td><td>588,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>840,0</td><td>100,8*</td><td>151,2*</td><td>588,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>840,0</td><td>100,8*</td><td>151,2*</td><td>588,0</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>4 800,0</td><td>633,84*</td><td>842,16*</td><td>3 324,0</td></tr>
</table>
*Татарстан Республикасы бюджетыннан Дәүләт программасы юнәлешләре буенча бүлеп бирелә торган акчаларның суммасы ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә аныкланачак.<br>Программаны гамәлгә ашыруны федераль бюджет акчалары исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау шартларында ел саен төзелә торган килешүләр нигезендә федераль хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында билгеләнәчәк</td></tr>
<tr><td>Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре</td><td>2024 елга арттырырга:<br>яңа АГТКС саны, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып, 40 берәмлеккә;<br>яңа КриоАЗС санын 12 берәмлеккә;<br>КТГ һәм СТГ заправкасы буенча блоклар урнаштыру белән гамәлдәге АЗС саны, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып, 10 берәмлеккә»;</td></tr>
</table>

Программаның 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

КТГны газ-мотор ягулыгы сыйфатында куллану нефть ягулыгын куллануга перспектив альтернатива булып тора.

КТГда эшләүче автомобильләрнең дөньякүләм паркы 28,1 млн. берәмлек тәшкил итә.

Россия Федерациясендә 59,22 млн. берәмлектән артык транспорт чарасы теркәлгән, шуларның 239 мең берәмлеге (гомуми санның 0,40 проценты) КТПГны газ-мотор ягулыгы сыйфатында куллана.

2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгын (метанны) 11,3 мең берәмлектән артык транспорт чарасы файдаланыла.

КТГны газ-мотор ягулыгы сыйфатында куллануның иң зур потенциалы ачыкланган:

эре сәнәгать автотранспорт предприятиеләре, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре урнашкан республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә (Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә);

төбәк йөк ташу һәм пассажирлар йөртү компанияләре, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы муниципаль предприятиеләре урнашкан муниципаль районнарда (Азнакай, Әлмәт, Буа, Бөгелмә, Биектау, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Лениногорск, Тукай);

Татарстан Республикасының эре автоюл предприятиеләрен үз эченә алган автотранспорт комплексында;

Татарстан Республикасының эре агросәнәгать холдингларын, агросәнәгать предприятиеләрен һәм крестьян-фермер хуҗалыкларын үз эченә алган агросәнәгать комплексында;

1 нче таблицада китерелгән Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында. Республикада төбәк һәм федераль әһәмияткә ия автомобиль юлларының озынлыгы 14 729,1 километр тәшкил итә.

1 нче таблица

Татарстан Республикасы территориясе буйлап узучы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары, хәрәкәтнең югары интенсивлыгы белән

| Т/с | Автомобиль юлы исеме | Хәрәкәтнең уртача тәүлеклек киеренкелеге, автомобиль/тәүлек |
|---|---|---|
| 1. | М-7 «Волга» Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород – Казан - Уфа | 18 657 |
| 2. | Р-239 Казан - Оренбург - Акбүләк Казахстан Республикасы белән чиккә кадәр | 14 136 |
| 3. | Р-239 Казан - Оренбург - Акбүләк Казахстан Республикасы белән чиккә кадәр, «Казан» аэропортына килү юлы | 11 204 |
| 4. | Р-241 Казан - Буа - Ульяновск | 6 779 |
| 5. | А-295 Йошкар-Ола - Зеленодольск - М-7 “Идел” автомобиль юлы | 41 705 |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Төзелә торган автомобиль юллары:<br>Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу участогында Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа М-7 «Идел» автомобиль юлы | – |
| | Мәскәү - Түбән Новгород - Казан зур тизлекле М-12 автомобиль юлы | |

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы сыйфатында КТГ һәм СТГ куллану юнәлешен үстерү максатында түбәндәгеләр кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла:

«Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013 - 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 04 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасы.

Күрсәтелгән программаларның төп максаты – автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтысы дәрәҗәсен тотрыклы киметүне тәэмин итү һәм автотранспорт чаралары белән ташуның иң зур икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешү, шулай ук транспорт чараларын газга (метанга) сатып алу һәм яңадан җиһазлау исәбенә Татарстан Республикасы автотранспорт паркын яңарту һәм мотор ягулыгы буларак КТГ (метан) һәм СТГ куллануны арттыру.

Татарстан Республикасында АГТКС төзү эшләрен активлаштыру һәм транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен кирәкле шартлар тудыручы түбәндәге федераль һәм региональ норматив хокукый актлар кабул ителде:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 елда газ-мотор ягулыгы базарын үстерү чараларын гамәлгә ашыру максатларында финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 18 октябрендәге 1344 номерлы карары.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджеттан сыекландырылган табигый газның җитештерү һәм ягулык салу инфраструктурасы объектларын төзү буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга чыгымнар өлешен каплауга

юридик затларга субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 29 августындагы 1308 номерлы карары.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә аз тонналы сыеклandырылган табигый газ һәм газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында 2021 елның 13 февралендәге 350-б номерлы боерыгы.

5. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясендә сыекландырылган табигый газ җитештерүне үстерүнең озак сроклы программасы турында 2021 елның 16 мартындагы 640-б номерлы боерыгы.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре бирү турында» 2017 елның 17 апрелендәге 234 номерлы боерыгы.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре бирү турында» 2020 елның 2 маендагы 161 нче боерыгы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре бирү турында» 2021 елның 12 декабрендәге 295 номерлы боерыгы.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Масштаблы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлекләре бирү турында» 2021 елның 22 декабрендәге 342 номерлы боерыгы.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары.

12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Транспорт чараларына кысылган табигый газ салу объектларын төзүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муни-ципаль) учреждениеләрдән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1008 нче карары.

13. Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте арасында газ-мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны куллануны киңәйтү турында 2021 елның 15 октябрендәге 1089-с номерлы килешү.

Татарстан Республикасы территориясендә югары, урта һәм түбән басымлы газүткәргечләрнең тармакланган челтәре эшли. Шул ук вакытта АГТКС гамәлдәге челтәре республиканың бөтен территориясендә газ-мотор техникасы өчен транспорт маршрутларын оештырырга мөмкинлек бирми. Әлеге проблеманы хәл итү өчен АГТКС, КриоАЗС төзү һәм гамәлдәге АЗСларны КТГ һәм СТГ заправкасы блокларын урнаштыру белән реконструкцияләү каралган.

2021 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында төрле типтагы 37 АГТКС кулланыла:

«Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең урта идел филиалы - 25 АГТКС;

«Атлант» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять - 3 АГТКС;

«Татнефть АЗС - Үзәк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте - 2 күп ягулык АЗС, КТГ блогы белән;

«РариТЭК Технологии» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять - 2 АГТКС;

«Газпром Трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте - 1 ябык типтагы АГТКС (Шәмәрдән пос.);

«Каматранснефть» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте - КТГ блогы белән 1 күп ягулык АЗС;

«Меркурий» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте - КТГ блогы белән 1 күп ягулык АЗС;

«Чаллы Икмәк» акционер җәмгыяте - 1 АГТКС;

«Минзәлә-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять - 1 АГТКС.

2012 - 2021 елларда мотор ягулыгы сыйфатында КТГ куллану:

| Ел | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| КТГ куллану, млн.куб.метр | 4,5 | 7,2 | 10,7 | 14,2 | 22,8 | 28,6 | 35,7 | 50,3 | 54,4 | 67,4 |

Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарының алга таба үсешен 2024 елга кадәр кимендә 40 АГТКС (2019 - 2021 еллар чорында 15 АГТКС кертелде), кимендә 12 КриоАЗС (2019 - 2021 еллар чорында 2 КриоАЗС кертелде), КТГ һәм СТГ ягулык салу блоклары урнаштыру белән гамәлдәге 10 АЗС тан да ким булмаган күләмдә реконструкцияләнә (2019 - 2021 еллар чорында гамәлдәге күп ягулык АЗСларында КПГ блогы кертелде) эре торак пунктларда, сәнәгать үзәкләрендә һәм транспорт магистральләрендә.

2018 ел бәяләрендә 5,9 млн.куб.метрлы бер АГТКС төзү бәясе 120,0 млн. сум тәшкил иткән.

2019 - 2021 елларда АГТКСның гамәлдәге челтәрен киңәйтү максатларында федераль бюджеттан 40,0 млн. сум күләмендә бер газ заправкасы инфраструктурасы объектын төзү һәм файдалануга кертү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашу каралган иде, хәзерге вакытта субсидия күләме 36,0 млн. сум тәшкил итә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына 28 нче кушымтада каралган КТГ транспорт чараларын ягулык салу объектларына таләпләр үтәлгән шартларда. Әлеге программа кысаларында елына кимендә 7 АГТКС төзелергә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә коммерция нигезендә төрле ягулыкны гамәлгә ашыручы 905 гамәлдәге автомобиль ягулыгы инфраструктурасы объекты урнашкан, шул исәптән 37 АГТКС, 2 КриоАЗС (2021 елның 31 декабренә булган мәгълүматларга караганда). КриоАЗС төзү буенча проектларны гамәлгә

ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 04 декабрь, 954 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану» дәүләт программасы ярдәмендә башкарыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2020 елдан бирле «Газпром» ГАҖ оешмаларыннан тыш, республиканың газ-мотор ягулыгы базарына кече һәм урта предприятиеләр дә килде, бүгенге көндә табигый газ (метан) «Каматранснефть» ҖЧҖ, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «Магистраль» ҖЧҖ кебек компанияләрдә гамәлгә ашырыла.

2021 елда В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ реконструкцияләнде һәм КТГ газ блоклары булган 2 күп ягулык АЗС файдалануга тапшырылды: Питрәч муниципаль районында 8 нче күп ягулык АЗС һәм Түбән Камада 403 нче күп ягулык АЗС. Компания 2022 - 2023 елларда КТГ блокларын урнаштыру белән АЗС челтәрен реконструкцияләүне дәвам итәчәк.

Зеленодольск муниципаль районында «Меркурий» ҖЧҖ «Магистраль» ҖЧҖнең күп ягулык АЗС территориясендә (Осиново авыл җирлеге, «Идел» М-7 федераль трассасының 788 км) КТГ блогын төзү проектын гамәлгә ашырды.

«Каматранснефть» ҖЧҖ 2020 елда Актаныш муниципаль районында «Кама-Транснефть»АЗС ында (Иске Байсар авыл җирлеге) КТГ блогын төзү проектын гамәлгә ашырды.

2022 елда республиканың автомобильләргә ягулык салу инфраструктурасының кече һәм урта предприятиеләре (ШЭ И.И.Баров, Агрофирма Илик, ШЭТ.К.Шәрипов) АГТКС төзү эшләрен дәвам итәчәк.

Моннан тыш, республикада СТГ тормышка ашыру өчен инфраструктура төзү эше алып барыла. Республика территориясендә 2 КриоАЗС («Новатэк» ГАҖ һәм «Газпром СПГ Технологии» ҖЧҖ) Чаллыда һәм Югары Ослан муниципаль районында «Свияжские Холмы» тау чаңгысы комплексы территориясендә (2021 елның 31 декабре мәгълүматлары буенча) файдаланыла.

Республикада СТГ техника паркы 50 берәмлектән артып китте (2021 елның 31 декабренә булган мәгълүматларга караганда). 2022 елда сыекландырылган табигый газ җитештерү буенча ике заводны (Теләче һәм Биектау муниципаль районнарында) файдалануга тапшыру һәм 7 КриоАЗС төзү планлаштырыла.

Татарстан Республикасы автотранспорт һәм агросәнәгать комплекслары предприятиеләрен КТГ һәм СТГ тәэмин итү өчен шулай ук күчмә автомобиль газ заправщикларын (алга таба - ПАГЗ) урнаштыру планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында автотранспорт техникасын (шул исәптән транзит автотранспортын) ягулык белән тәэмин итү максатларында ПАГЗ файдалануга тапшырылды. Әлеге проект 2019 елда гамәлгә ашырылды. Эксплуатацияләү йомгаклары буенча «РариТЭК Технологии» ҖЧҖ компаниясе тарафыннан 2021 елда АГТКС төзү турында карар кабул ителде, әлеге проект уңышлы гамәлгә ашырылды.

ПАГЗ - составына газ аккумуляторлары, газны коммерцияле исәпкә алган газ заправкасы колонкасы, заправка автотехникасының автомат идарәсе системасы һәм тизләтелгән ягулык салу станциясе кергән махсус транспорт чарасы. ПАГЗ стационар

АГТКСтан читтә эшләүче транспорт чараларына табигый газ белән ягулык салу өчен билгеләнгән.»;

Программаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Программаның төп максаты һәм бурычлары, гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын күрсәтеп

Программаның максаты - республикада газ ягулыгы салу инфраструктурасын киңәйтү юлы белән КТГ эшләүче транспорт чараларын күчерүне һәм сатып алуны стимуллаштыру, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булган күп ягулык АЗСларында булуны исәпкә алып.

Программаны гамәлгә ашыру барышында түбәндәге мәсьәләне хәл итү каралган: күп ягулыклы АЗСларда яңа АГТКС һәм КТГ блокларын төзү һәм файдалануга кертү, шул исәптән электр двигательләре белән транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып.

Программа биш этапта тормышка ашырыла.

I этап (2019 ел).

Этапның чаралары түбәндәгеләрне кертә:

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм аларга бүлеп бирү;

ресурслар белән тәэмин итү чыганакларын билгеләү;

2 АГТКС төзү һәм кулланышка кертү.

II этап (2020 ел).

Этапның чаралары түбәндәгеләрне кертә:

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм аларга бүлеп бирү;

6 АГТКС төзү һәм кулланышка кертү, КТГ гамәлдәге 1 күп ягулык АЗСларына ягулык салу блогын урнаштыру.

III этап - 2021 ел.

Этапның чаралары түбәндәгеләрне кертә:

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм аларга бүлеп бирү;

7 АГТКС төзү һәм кулланышка кертү, гамәлдәге 3 АЗС реконструкцияләү, КТГ заправкасы буенча блоклар урнаштыру белән.

IV этап - 2022 ел.

Этапның чаралары түбәндәгеләрне кертә:

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм аларга бүлеп бирү;

7 АГТКС төзү һәм файдалануга тапшыру.

V этап - 2023 - 2024 еллар.

Этапның чаралары түбәндәгеләрне кертә:

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм аларга бүлеп бирү;

7 АГТКС төзү һәм файдалануга тапшыру.

Зур торак пунктларда, сәнәгать үзәкләрендә һәм транспорт автомагистральләре янында АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен килештерү һәм бүлеп бирү өстенлекле программа чарасы булып тора.

АГТКС төзү өчен җир кишәрлекләрен сайлау критерийлары:

«Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тәкъдимнәренә (2016 елның 11 апрелендәге директива) һәм гамәлдәге күп ягулык АЗСларына газ модульләре төзүдә махсуслашкан башка эре нефть эшкәртү компанияләре АГТКС урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләренең параметрлары өлешендә туры килү;

эре шәһәрләргә һәм сәнәгать үзәкләренә, автотранспорт һәм агросәнәгать комплекслары предприятиеләренә якын урнашу;

федераль һәм республика әһәмиятендәге автотранспорт магистральләренә якын урнашу;

газ, су һәм электр белән тәэмин итүнең инженерлык челтәрләренә якынлыгы һәм аларга тоташу мөмкинлеге.

Төзелешнең яңа объектыннан (АГТКС) гамәлдәге АГТКС кадәр гамәлдәге юллар буйлап ераклык булырга тиеш:

федераль әһәмияттәге автомобиль юлының бер ягы буйлап кимендә 15 км;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлының бер ягы буйлап кимендә 10 км;

торак пунктта автомобиль юлының бер ягы буйлап кимендә 3 км.

Әлеге критерийлар нигезендә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә КТГ заправка инфраструктурасының гамәлдәге һәм перспективалы объектларын урнаштыруның оптималь схемасы эшләнде (Программага 2 нче кушымта).»;

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «3. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

40 АГТКС төзү һәм файдалануга тапшыру программасын финанслауның гомуми күләме 4 800,0 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акча - 633,84 млн.сум;

федераль бюджет акчасы - 842,16 млн.сум;

бюджеттан тыш чыганаклардан - 3 324,0 млн.сум.

(млн.сум)

| Ел | Барлыгы акча | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджет акчасы | Бюджеттан тыш чыганаклардан акча |
|---|---|---|---|---|
| 2019 | 240,0 | 0 | 80,0 | 160,0 |
| 2020 | 840,0 | 117,6 | 162,4 | 560,0 |
| 2021 | 1 200,0 | 213,84 | 146,16 | 840,0 |
| 2022 | 840,0 | 100,8 | 151,2 | 588,0 |
| 2023 | 840,0 | 100,8 | 151,2 | 588,0 |
| 2024 | 840,0 | 100,8 | 151,2 | 588,0 |
| Барысы | 4 800,0 | 633,84 | 842,16 | 3 324,0»; |

Программаның 6 бүлегендә 4 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 нче таблица

Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре

| Күрсәткеч исеме | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Яңа АГТКС саны, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып (үсә барган нәтиҗә белән); | 2 | 9 | 19 | 26 | 33 | 40. |

Программага кушымтаны 1 нче кушымта дип санарга һәм яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Программага 2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы
территориясендә автомобильләргә газ сала
торган
компрессорлы станцияләр төзү»
Татарстан Республикасы
дәүләт программасына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 апрель, 385 нче карары
редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә компримировкаланган табигый газ ягулык салу инфраструктурасының гамәлдәге һәм перспективалы объектларын территориаль яктан урнаштыру схемасы*




**Гамәлдәге АГНКС (37 берәмлек)**:**

Казан - 6 берәмлек
Чаллы - 4 берәмлек
Түбән Кама - 3 берәмлек
Зеленодольск районы - 3 берәмлек
Әлмәт - 2 берәмлек
Бөгелмә - 1 берәмлек
Мамадыш районы - 1 берәмлек
Буа - 1 берәмлек
Алабуга - 1 берәмлек
Азнакай - 1 берәмлек
Алексеевск - 1 берәмлек
Лениногорск - 1 берәмлек
Зәй - 1 берәмлек
Нурлат - 1 берәмлек
Актаныш районы - 1 берәмлек
Минзәлә районы - 1 берәмлек
Шәмәрдән (Арча компрессор станциясе) - 1 берәмлек
Апас районы - 1 берәмлек
Әлки районы - 1 берәмлек
Лаеш районы - 1 берәмлек
Питрәч районы - 2 берәмлек
Тукай районы - 1 берәмлек
Менделеевск районы - 1 берәмлек

**2022 - 2024 елларда инфраструктураны үстерү**
**Яңа АГНКС төзелеше (16 берәмлек):**

Чаллы - 2 берәмлек
Түбән Кама - 1 берәмлек
Арча районы - 1 берәмлек
Баулы районы - 1 берәмлек
Биектау районы - 2 берәмлек
Алабуга районы - 2 берәмлек
Зеленодольск районы - 2 берәмлек
Лаеш районы - 2 берәмлек
Минзәлә районы - 1 берәмлек
Питрәч районы - 1 берәмлек
Саба районы - 1 берәмлек

Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 17 апрелендәге 234 номерлы боерыгы нигезендә бүлеп бирелгән һәм хәзерге вакытта файдаланылмый торган җир кишәрлекләре

Татарстан Республикасы территориясендә сыекландырылган табигый газның ягулык салу инфраструктурасының гамәлдәге һәм перспективалы объектларын территориаль яктан урнаштыру схемасы*




**Гамәлдәге КриоАЗС **(2 берәмлек):**

Чаллы - 1 берәмлек
Югары Ослан районы - 1 берәмлек

**2022 - 2023 елларда инфраструктураны үстерү**

**КриоАЗС һәм КриоПАГЗ яңа төзелеше (8 берәмлек):**

Баулы районы - 1 берәмлек
Балык Бистәсе районы - 2 берәмлек
Зеленодольск районы - 1 берәмлек
Лаеш районы - 1 берәмлек
Питрәч районы - 2 берәмлек
Чаллы - 1 берәмлек

**СПГ җитештерү заводларын төзү (3 берәмлек):**

Биектау районы - 1 берәмлек
Алабуга районы - 1 берәмлек
Теләче районы - 1 берәмлек

---

*Схема елына бер тапкырдан да сирәгрәк актуальләштерелми.
**2021 елның 31 декабренә торышы буенча.

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 апрель, 385 нче карары редакциясендә)

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә автомобильләргә газ сала торган компрессорлы станцияләр төзү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, финанслау күләмнәре

| Төп чара исеме | Җаваплы башкаручылар | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы | Финанслау, млн.сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| Максат: электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып, республикада газ ягулыгы инфраструктурасын киңәйтү юлы белән КТГ* эшләүче автомобиль техникасын күчерүне һәм сатып алуны стимуллаштыру | | | | | | | | | | | | | | | |
| Задача: Строительство и ввод в эксплуатацию новых АГНКС с зарядными колонками (станциями) для транспортных средЭлектр двигательләре белән ств | | | | | | | | | | | | | | | |
| АГНКС төзү һәм эксплуата-циягә кертү | «Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖнең Урта Идел филиалы (килешү буенча), бәйсез АЗС (килешү буенча), «Татнефть» ГАҖ (килешү буенча), ТР СhСМ, ТР ҖҮО, оешмалар (килешү буенча) | Яңа АГНКС саны, шул исәптән электр двигательләре булган транспорт чаралары өчен заряд колонкалары (станцияләре) булуны исәпкә алып (үсә торган нәтиҗә белән) | 2 | 9 | 19 | 26 | 33 | 40 | ФБ | 80,0 | 162,4 | 146,16 | 151,2 | 151,2 | 151,2 |
| | | | | | | | | | ТРБ | 0 | 117,6 | 213,84 | 100,8 | 100,8 | 100,8 |
| | | | | | | | | | БТЧ | 160,0 | 560,0 | 840,0 | 588,0 | 588,0 | 588,0 |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 2 нче биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы<br>шул исәптән: | | | | | | | | | | 240,0 | 840,0 | 1 200,0 | 840,0 | 840,0 | 840,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | 0 | 117,6 | 213,84 | 100,8 | 100,8 | 100,8 |
| федераль бюджет | | | | | | | | | | 80,0 | 162,4 | 146,16 | 151,2 | 151,2 | 151,2 |
| бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | | | | | 160,0 | 560,0 | 840,0 | 588,0 | 588,0 | 588,0 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

АГТКС - автомобильне газ белән тутыра торган компрессор станциясе;
АЗС - автомобиль ягулык салу станциясе;
ТРБ – Татарстан Республикасы бюджеты;
БТЧ - бюджеттан тыш чыганаклар;
КТГ - компримировкаланган табигый газ;
ТР СhСМ - Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;
ТР МБ - Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре;
«Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖнең Урта Идел филиалы - «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең Идел буе филиалы;
«Татнефть» ГАҖ - В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте;
ФБ - федераль бюджет.